Республика Татарстан
Глава Тураевского
сельского поселения
Менделеевского
муниципального района
423647, селоТураево,
ул. Центральная, 11А

Татарстан Республикасы
Менделеев
муниципаль районы
Турай авыл жирлеге
башкарма комитеты
423647, Турай авылы,
Узәк урам, 11А

Тел./факс 2-73-31

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.11.2023 ел № 9

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Турай авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, « Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,

**Карар бирәм:**

1. 2023 елның 28 ноябре 10.00 сәгатьтә Турай авыл җирлегенең Турай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2023 елның 28 ноябре 11.00 сәгатьтә Турай авыл җирлегенең Турай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2023 елның 28 ноябре 12.00 сәгатьтә Турай авыл җирлегенең Турай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. 2023 елның 28 ноябре 12.00 сәгатьтә Турай авыл җирлегенең Турай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

Җыеннарның барлык этапларын үткәрү урыны итеп Турай авылы, Үзәк урам, 11А йорты буенча урнашкан Турай авыл мәдәният йортын билгеләргә.

Турай халкы исемлеген этапларга аеруны территориаль билгеләр буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

Беренче этап: улица Кама урамы 1 йорттан 4 йортка кадәр, Яңа урам 1 йорттан 3 йортка кадәр, Яшьләр урамы 8,10, 21 йорт, Окольная урамы 1 йорттан 37 йортка кадәр

Икенче этап: Овражная урамы 1 йорттан 37 йортка кадәр, Совет урамы 1 йорттан 33 йортка кадәр

Өченче этап: Үзәк урам, 1 йорттан 44 йортка кадәр, Крайняя урамы 1 йорттан 33 йортка кадәр

Дүртенче этап: Тынычлык урамы 1 йорттан 18 йортка кадәр, Мәктәп урамы 1 йорттан 12 йортка кадәр

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2024 елда Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлегенең Турай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, ә күп балалы гаиләләрдән 50% ка киметеп 500 сум күләмендә билгеләргә, I-II төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларга тиңләштерелгәннәрне, көндезге бүлектә укучы студентларны, махсус хәрби операциядә катнашучыларны түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы:

1. Турай авылында урам яктырткычлары урнаштыру.
2. Су насосын сатып алу.
3. Су насосын сатып алу.
4. Үлән чабу.
5. Чылбырлы бензопила сатып алу
6. Турай авылы зираты территориясендә агачларны кисү
7. Турай авылы спорт мәйданчыгы өчен материал сатып алу һәм койма урнаштыру
8. Турай авылында кышкы чорда карны чистарту.
9. Янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру.
10. Яңа су башнясына койма урнаштыру.

« Риза» "Каршы"

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru «Турай авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Турай авыл җирлеге башлыгы Г.Б. Куляшова